**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

**Предмет нәтиҗәләре**

**1 <u>класс</u>**

**<u>Укучы өйрәнә</u>**

Аваз һәм хәрефләрне аера; татар телендәге авазларга характеристика бирә белә; сузык авазларның калын һәм нечкә, тартык авазларның яңгырау һәм саңгырау булуын белә;баш һәм юл хәрефләренең язылышын үзләштерә; аерым хәрефләрне, аларның кушылмаларын, иҗекләрне, сүзләрне, җөмләләрне графика, каллиграфия, гигиена кагыйдәләре таләп иткәнчә яза; әйтелеше язылышына туры килгән сүзләрне ишетеп яза; хәрефләрне алфавит тәртибендә дөрес итеп әйтә.

Сүзнең мәгънәгә ия булуы өчен авазларның билгеле тәртиптә урнашуын аңлый;сүзләрне авазларга тарката, авазларны сүздәге тәртиптә әйтә белә.

Предметны, аның эшен, хәрәкәтен, төрле билгеләрен атаган сүзләрне аера белә.

Сүзләрне юлдан-юлга күчерә белә; җөмләдәге сүзләрне аерып яза белә; җөмлә башында һәм ялгызлык исемнәрдә баш хәреф яза белә; тактадан һәм китаптан текстны дөрес итеп күчереп яза белә; дөрес язу кагыйдәләрен өйрәнелгән күләмдә куллана белә; өйрәнелгән дөрес язу кагыйдәләренә туры килгән 10-15 сүзле текстны укытучы әйтеп торганда яза белә.

Җөмлә һәм текстны, сүзтезмә һәм сүзләрне аера белә***; тексттан җөмләләрне аерып ала*** *белә****; җөмләләрнең схемасын, схемаларга туры килгән җөмләләрне аера*** белә***; сүзләрдән җөмләләр төзи*** белә***; схемалар, рәсемнәр буенча җөмләләр төзи*** белә***; җөмлә башында баш хәреф, җөмлә ахырында нокта куя*** белә**.**

Аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайлый белә;көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес куллана белә; тәкъдим ителгәннәр арасыннан текстка исем сайлый белә; бирелгән җөмләләрдән текст төзи белә; сорауларны тыңлый, аңлый, дөрес җавап бирә белә.

**<u>Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак</u>**

Сүзлектән карап, сүзнең язылышын ачыкларга; аваз һәм хәреф саны туры килмәү очракларын билгеләргә.

Сүзнең мәгънәсен тануда сүз басымының әһәмиятен аңларга.

Тәкъдим ителгән тексттан өйрәнелгән сүз төркемнәрен табарга.

Орфографик хата җибәрү ихтималы булган урынны ачыкларга; э,о,ө,й,е,ю,я, к,г хәрефләре, йө,йо кушылмалары булган сүзләрне дөрес язарга;сүзләрне орфоэпик укыганда, әйтелеше һәм язылышы туры килмәү очракларын билгеләргә.

Укытучы ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга; җөмләләрнең мәгънәви-интонацион үзенчәлекләрен күзәтергә.

Рәсем буенча 2-3 җөмләдән торган хикәя төзи һәм язарга.

**2 <u>класс Укучы</u>**

**<u>өйрәнә</u>**

Аваз һәм хәрефләрне аера,ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә ала.

Хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана ала.

Сүзнең тамырын, тамырдаш сүзләрне. Кушымчалар.Татар телендә сүз тамырының сүз башында булуын, үзгәрмәвен, кушымчаларның тамыр сүзгә сингармонизм законына бәйле рәвештә ялганып килүен гамәли күзәтү.

Предметны белдергән сүзләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр.Кеше исемнәрен, фамилияларын, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.Эш – хәрәкәтне белдергән сүзләр. Аларның җөмләдә сүзләрне үз тирәсенә туплаган үзәк булуына төшенү. Предметларның төрле билгеләрен атаган сүзләр. Аларны нинди? кайсы? Сорауларын куеп, сүзләр арасыннан табу, җөмләдәге ролен гамәли күзәтү.

Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга, сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга.

Җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә,тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә өйрәнә.

Дөрес язу кагыйдәләрен өйрәнелгән күләмдә куллану, сүзнең дөрес язылышын орфографик сүзлектән карап билгели, 8-13 сүзлек текстны күчереп яза, өйрәнелгән кагыйдәләргә туры килгән 20-25 сүзле диктант ите яза, үзе язган текстагы орфографик һәм пунктуацион хаталарны таба һәм төзәтә.

Аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга, көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес кулланырга,аралашу ситуациясен исәпкә алып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә,текстка исем бирергә,укылган яки тыңлаган текстның планын төзергә, аерым аралашу ситуацияләренә туры китереп, хат яки тәбрикләү хаты кебек кечкенә текстлар язарга өйрәнә

**<u>Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак</u>**

Сүзләргә фонетик-график анализ ясый, дәреслектәге үрнәк буенча сүзләрне тикшерә һәм аның дөреслеген дәлилли, дәреслектәге җирелгән материал күләмендә укучы үзенең һәм әңгәмәдәше сөйләмендә татар әдәби теле нормаларын саклый, сүзне дөрес әйтү-әйтмүве яки сүз басымын дөрес кую-куймавы хакында икеләнгән очракта, укучы үз җавабаның дөрелеген дәреслектәге сүзлекчәдән карап яки укытучыдан мөстәкыйль рәвештә сорап ала белә.

Мәгънәле кисәкләрнең чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен дәреслктә бирелгән күләмдә тикшерә, сүзнең дөрес тикшерелеүен бәяли белә.

Текстта кабатлаулар булмасын өчен, аерым сүләрнең синомнарын таба, предмет, күренеш һәм төшенчәләргә чагыштырма характеристика бирү өчен, антонимнар таба, текста(җөмләдә) сүзләрнең туры яки күчерелмә мәгънәсен аера белә, текста(җөмләдә) сүзләрнең урынлы куллану-кулланмавын аера белә, аралашканда кулланыр өчен кирәкле сүзләрне дөрес сайлый.

Өйрәнелгән сүз төркемнәренә дәреслектә бирелгән материал күләмендә морфологик анализ ясый, аның дөреслеген бәяли, тәкъдим ителгән тексттан(җөмләдән) өйрәнелгән сүз төркемнәрен таба.

Гади җөмләләргә дәреслектә бирелгән күләмдә синтаксис анализ ясый,тикшерүнең дөреслеген бәяли,гади, кушма җөмләләрне аера.
Орфографик хата җибәрү ихтималы булган урыннарны белә, тиешле орфограммага туры килгән мисалларны сайлый, текст төзегәндә аны орфографик һәм пунктуацион хаталар җибәрмәслек итеп үзгәртә ала, хаталар төзәткәндә аларның сәбәпләрен аңлый, алга таба хата җибәрмәү юлларын ачыклый.

Тектның эчтәлеген башака зат исеменнән сөйли, аерым темага караган сурәтләү, хикәяләү характерындагы хикәяне телдән төзи, изложение һәм сочинение язуның өйрәнелгән тәртибен саклый, язган изложение тексты белән төп варианты чагыштыра, сочинение язганда алга куелган максат һәм бурычларның үтәлешен билгели, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен үти.

**3 класс <u>Укучы</u>**

**<u>өйрәнә</u>**

Аваз һәм хәрефләрне аера;ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирергә өйрәнә; хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны кулланырга өйрәнә.

Кушымчаларның төрләрен (сүз ясагыч һәм сүз төрләндергеч кушымчалар), сүз формаларын һәм яңа сүзләр, аларның ясалышын чагыштырырга өйрәнә.

Исемнәрнең сан, килеш тартым белән төрләнешен; сыйфатларның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләрен; фигыльнең лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнә Дөрес язылыш кагыйдәләрен өйрәнгән күләмдә кулланырга;сүзләрнең дөрес язылышын орфографик сүзлек буенча ачыкларга;60–65 сүзле

текстны дөрес итеп күчереп язарга;өйрәнелгән дөрес язу кагыйдәләренә туры килгән 55-60 сүзле текстны укытучы әйтеп торганда язарга;үзе төзегән һәм тәкъдим ителгән текстны тикшерергә, орфографик һәм пунктуацион хаталарны табарга һәм төзәтергә өйрәнә

Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга,сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга,җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга;җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен белергә.

Аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга,көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес кулланырга, аралашу ситуациясен исәпкә алып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә,текстка исем бирергә, укылган яки тыңлаган текстның планын төзергә,бирелгән тема буенча текстлар язарга өйрәнә. Тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә өйрәнә.

**<u>Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак</u>**

Дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча сүзгә мөстәкыйль рәвештә фонетик-график (аваз-хәреф) анализ ясый, сүзгә ясалган фонетик-график анализның дөреслеген бәяли; сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба, яки укытучысына һәм әти-әнисенә мөрәҗәгать итә белү.

Укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен тикшерү һәм аның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге ала.

Укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча исемгә, сыйфатка, фигыльгә морфологик анализ ясый һәм аның дөреслеген бәяләү, тексттан алмашлык, рәвеш, бәйлек сүзләр, кисәкчә, теркәгечләрне, фигыльләрдәге юклык кушымчаларын (-ма / -мә) табу мөмкинлеге ала. Орфографик хата ясау мөмкинлеге булган очракларны аңлау, аерым орфограммаларга мисаллар сайлау, текстлар төзегәндә орфографик һәм пунктуацион хаталарны булдырмау өчен, язганнарны үзгәртү, хаталар өстендә эшләгәндә, аларның сәбәпләренә төшенү һәм алдагы язма эшләрдә хата җибәрмәү юлларын ачыклау мөмкинлеге алу.

Укучы җөмләнең иярчен кисәкләрен – аергыч, тәмамлык, хәлләрне аеру,дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча гади җөмләгә синтаксик анализ (җөмлә кисәкләре буенча) ясау һәм аны тикшерүнең дәреслеген бәяли, гади һәм кушма җөмләләрне бер-береннән аера белә. Тәкъдим ителгән исемнең эчтәлегенә туры килгән текст төзү, бирелгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү, сөйләмнең сурәтләү, хикәяләү, фикер йөртү кебек төрләрен кулланып, билгеле бер тема буенча телдән хикәя төзи, урыннары алышынган җөмләләрдән торган текстны тикшерү һәм төзәтү, аның мәгънә бөтенлеге югалган урыннарын таба, хаталы текстларга төзәтмә кертү, төрле төрдәге изложение яки сочинение язганда, эшне эзлекле алып бару, аны тикшерү һәм бирелгән үрнәк белән чагыштыру мөмкинлеген белү.

**4 класс. <u>Укучы өйрәнә.</u>**

Аваз һәм хәрефләрне аера,ана теленең авазларын һәм хәрефләрен язылыш үзенчәлекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә ала. Хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана алу.

Мәгънәсе ачыклану таләп итә торган сүзләрне табарга, текст буенча сүзләрнең мәгънәсен аера яисә аны аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачыкларга өйрәнә.

Тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларын аерырга, сүзнең тамыр һәм кушымчаларын (аффиксларын) табарга.

Исемнәрнең сан, килеш һәм тартым белән төрләнешен, сыйфатларның лексик-симантик һәм морфологик үзенчәлекләрен, фигыльнең лексик-симантик һәм морфологик үзенчәлекләрен өйрәнә.

Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга, сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга,җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга,җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгаләргә, тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонация буенча билгеләргә өйрәнә.

Аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга, татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес кулланырга , аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, текстка карата мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә, текстка исем бирергә, планын төзергә, хат яки тәбрикләү хаты кекбк кечкенә текстлар язарга өйрәнә.

**<u>Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак</u>**

Үз сөйләмендә татар әдәби тел нормаларын саклый һәм эңгәмәдәшенең сөйләмендә бу нормаларның дәреслектә бирелгән материал күләмендә үтелүен бәяли, сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба яки укытучысына яки әти –әнисенә мөрәҗәгать итә ала.

Текстларада кабатлаулар булдырмас өчен, кирәкле синонимнар, антонимнар табу, текстта туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне билгләү, аларның урынла кулланышын бәяләү, тәкъдим ителгән сүзләр арасыннан тиешлесен сайлап алу мөмкинлеген сайлап алу мөмкинлеге ала. Дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен тикшерү һәм аның дәреслеген бәяләү мөмкинлеге ала.

Дәреслктә ителгән үрнәк буенча исемгә, сыйфатка, фигыльгә морфологик анализ ясау һәм аның дөрслеген бәяләү, тексттан алмашлык, рәвеш,бәйлек сүзләр, кисәкчә, теркәгчләрне, фигыльдәге юклык кушымчаларын (-ма/-мә) табу мөмкинлеге ала.

Җөмләнең иярчен кисәкләрен- аергыч, тәмамлык,хәлләрне аеру, гади җөмләгә синтаксиз анализ (җөмлә кисәкләре буенча) ясау һәм аны тикшерүнең дөреслеген бәяләү, гади һәм кушма җөмләләрне бер-берсеннән аеру мөмкинлеге ала.

Тәкъдим ителгән исемнең эчтәлегенә туры килгән текст төзү, бирелгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү, сөйләмнең сүрәтләү, хикәяләү, фикер йөртү кебек төрләрен кулланып, билгеле бер тема буенча телдән хикәя төзү, урыннары алышынган җөмләләрдән торган текстны тикшерү, төзәтү, аның мәгънә бөтенлеге югалган урыннарын табу, хаталы текстларга төзәтмә кертү, изложение сочинение язганда, эшне эзлекле алып бару, аны тикшерү, бирелгән үрнәк белән чагыштыру, уку бурычларының дәреслеген бәяләү, үз текстын, аралашу максатын шартыннан чыгып, чыганак текст белән чагыштыру, электрон чыганаклардан файдаланганда, тел нормаларының үтәлешен саклау мөмкинлеге ала.

**Метапредмет нәтиҗәләре.**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**

1.Уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү.
2.Эш тәртибен аңлап, уку эшчәндеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү.
3.Уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү.
4.Укудагы уэышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү.
5.Ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру.
6.Дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнемәләрен үстерү

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

1.Логик фикерләү, сәбәп – нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү.
2.Иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру.
3.Объектларны чагыштыру , классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү.
4.Төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматны эчтәлегенә бәя бирә белү.
5.Тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

1.Әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү.
2.Әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү.
3.Аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре)
4.Парларда һәм күмәк эшли белү.
5.Мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару.
6.Әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре**

**1**.Шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленнә ихтирамлы караш булдыру һәа аны яхшы өйрәнү теләге тудыру.
2.Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрелеген аңлау.
3.Текстларда төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормларыннан чыгып бәя бирү.
4.‖Гаилә‖, ―туган ил‖,‖мәрхәмәтлелек‖ төшенчәләрен кабул итү, ―башакаларга карата түземлек, кайгыртучанлык‖ кебек хисләр формалашу.
5. Укучының тоткан урынын, укучы ролен кабул итү, укуга карата кызыксыну уяту, укуның шәхсән мәгънәсен аңлауны формалаштыру.

6. Әхлакый нормаларны кузаллауга нигезләнеп, укучының үз эшләгән эшләре өчен шәхси җаваплылыгын, мөстәкыйльлеген үстерү. 7.Эстетик ихтыяҗ һәм хис формалаштыру.
.

**ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ**

**1 нче сыйныф**

Беренче сыйныфта укучыларны грамотага өйрәтү ике чорга бүленә: грамотага әзерлек чоры, әлифба чоры ( төп чор). Грамотага өйрәтү үзара тыгыз бәйләнгән укый һәм яза белергә өйрәтүнең башлангыч процессыннан гыйбәрәт аналитик – синтетик аваз – хәреф методы белән тормышка ашырыла; авазлар һәм хәрефләр, иҗекләр һәм сүзләр, җөмләләр һәм бәйләнешле сөйләм өстендә эшләү күнегүләре аша ныгытыла. Аваз, хәреф — тану берәмлеге, иҗек — уку берәмлеге, сүз — аңлау берәмлеге, җөмлә — мәгълүмат-хәбәрлек берәмлеге (Кош оча. Балык йөзә.) икәнен гамәли аңлап, «чын уку һәм чын язу»ның җөмлә укудан һәм җөмлә язудан башланганын белеп эшләүләренә ирешелә.

**Грамотага әзерлек чоры**

Язу гигиенасы кагыйдәләре белән таныштыру, кагыйдәләрне даими үтәү гадәте тәрбияләү.Кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гому-ми күзаллау. Матур итеп сөйләшә, укый һәм яза белү кирәклеген аңлау.График схемалар ярдәмендә сөйләмне — җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру, сүзләрне иҗек һәм авазларга таркату. Дәфтәр битендә ориентлашу. Язу сызыгы, язуның башлангыч ноктасы. Структур берәмлек буларак кулланылган сызык элементлары.Алгоритм буенча сызык элементларын язу.

**Әлифба чоры, яки төп чор**

Барлык баш һәм юл хәрефләренең язылышы һәм аларның тоташтыруның төп сызыклары белән таныштыру һәм каллиграфик дөрес язарга өйрәтү. Язуда өч төрле (аскы,урта,өске) тоташтыру алымы. Авазларны сүздә тиешле язма хәрефләр белән күрсәтү. Сүздәге хәрефләрне, аларны тоташтырган сызыкларын әзмичә ритмик язуны булдыру , дәфтәр юлларына хәрефләрне һәм сүзләрне, тигез ара калдырып, тигез, дөрес урнаштыру. Башта укытучы белән иҗек –аваз анализы ясаганнан соң, тора бара мөстәкыйль рәвештә сүзләр, җөмләләр язу. Башта язмача, аннары басмача үрнәкләрдән сүзләр, җөмләләр күчереп язу. Үрнәк текст белән чагыштырып карау һәм сүзләрне иҗекләп орфографик уку ярдәмендә дәфтәргә язылганнарның дөреслеген тикшерү. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне, шундый өч-дүрт сүздән торган җөмләләрне диктант итеп язу.

**Татар теле дәресләре** әлифба курсы тәмамланганнан соң атнага 2 дәрес хисабыннан укытыла.

**Авазлар һәм хәрефләр**

Аваз һәм хәрефне аеру. Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан юлга күчерү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, юлдан-юлга күчерү билгесе кую, кызыл юл кебек график чараларны куллану. Алфавиттагы хәрефләрнең исемен дөрес әйтү, аларның урнашу тәртибен белү. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар , аларны белдерә торган

хәрефләрнең дөрес язылышы. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар.

**Синтаксис**Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру җөмләләр, аларны дөрес интонация белән уку. Җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре кую.

**Морфология**

Сүз төркемнәре турында төшенчә бирү. Предметны белдерүче сүзләр. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр, аларның язылышы. *Кем?Нәрсә?* сорауларына җавап биргән исемнәрне аеру. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр- бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр. Эш-хәрәкәтне белдерүче сүзләр. Билгене белдерүче сүзләр.

**Бәйләнешле сөйләм**

Иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү. Өч-дүрт җөмләдән торган хикәя төзеп язу. Рәсем буенча кечкенә хикәя төзү. Шигырь, табышмак, мәкальләрне ятлап хәтер диктанты язу.

**2 нче сыйныф**

**Фонетика һәм орфоэпия**

Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Язуда сузык авазларны белдерә торган хәрефләр. Аваз һәм хәрефләрне аеру. Сузык авазлар. Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре.

Яңгырау һәм саңгырау, парлы һәм парсыз тартыклар. Язуда тартык авазларны белдерә торган хәрефләр. Татар теленә генә хас булган [w], [гъ], [къ], [х], [ч]; [ж], [ң], [h] авазлары.

*Е, ю, я* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу.Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы.Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүе.*ъ* һәм *ь* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу һәм уку.

**Графика**

Татар алфавиты: хәрефләрнең тәртибен һәм исемен  яттан белү. Сүзлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү.

**Сүз**

Сүз тамыры. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар. Сүз ясалу үзенчәлекләре.Предметны белдергән сүзләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр. Аларның мәгънәсе һәм җөмләдә куллану үзенчәлекләре. Предметның билгесен белдергән сүзләр, аларны җөмләдә куллану. Татар телендә исем һәм сыйфатның синтаксик бәйләнеш үзенчәлеге.

Сүз, сүзтезмә һәм җөмлә. Сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Җыйнак һәм җәенке җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрләре, аларның дөрес әйтелеше.

**Бәйләнешле сөйләм**

Текстта җөмләләрнең урнашу тәртибе (үзара бәйләнеше). Текстның темасын билгеләү, төп фикерен табу. Текстны кисәкләргә бүлү һәм исем кую.Рәсемнәр буенча, терәк сүзләр кулланып, текст төзү. Тәкъдим ителгән бирем буенча текстның эчтәлеген сөйләү.Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау. Татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану.

**3 нче сыйныф**

**Лексика**. **Сүз.**

Сүз һәм аның лексик мәгънәсе.Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, аларның аермасы.Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре,аларны сөйләмдә куллану. Татар телендә алынма сүзләр.Синонимнар һәм антонимнар, омонимнар: аларны сөйләмдә куллану. Татар теленең сүзлек байлыгы.Татар телендә сүзлекләр: татар теленең аңлатмалы сүзлеге, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләре һәм аларны көндәлек тормышта , уку эшчәнлегендә куллану.

**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы**

Сүзнең мәгънәле кисәкләрен билгеләү: тамыр һәм кушымча. Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә. Сүзне төзелеше буенча тикшерү.Тамырдаш сүзләр турында төшенчә. Аларның синонимнардан һәм омонимнардан аермасы. Тамырдаш сүзләр һәм бер үк сүзнең төрле формалары.Сүзләрнең дөрес язылышын тикшерү ысуллары: сүзнең формасын үзгәртү, тамырдаш сүзләр сайлау, орфографик сүзлек куллану.

**Морфология**

Сүз төркемнәре турында төшенчә.

**Исем.** Мәгънәсе һәм кулланылышы. Берлек һәм күплек саннары. Күплек сан кушымчаларының дөрес язылышы. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәргә морфологик анализ ясау күнегүләре.

**Фигыль.** Фигыльнең мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Фигыльнең барлык һәм юклык формалары. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыльнең хәзерге, үткән һәм киләчәк заманнары. -ар, -әр, -ыр, -ер, -р, -ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк киләчәк заман хикәя фигыль кушымчаларының дөрес язылышын гамәли үзләштерү. Фигыльләргә морфологик анализ.

**Сыйфат.** Мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфат дәрәҗәләре: гади(төп), чагыштыру, артыклык, кимлек. Чагыштыру дәрәҗәсендәге –рак, -рәк кушымчаларының һәм артыклык дәрәҗәсендәге кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

**Алмашлык.** Алмашлык турында гомуми күзаллау.Зат алмашлыклары, мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше.

**Кисәкчә**. *да, дә, та, тә* кисәкчәләрен *–да, -дә, -та, -тә* урын-вакыт килеше кушымчаларыннан аерып таный белү ысуллары.Кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

**Бәйлекләр**, аларның сөйләмдәге әһәмияте. Бәйлекләрне исемнәр һәм алмашлыклар белән төрле килешләрдә куллану.

**Синтаксис**

**Җөмлә**. Әйтелү максатыннан чыгып, җөмләләрнең төрләре(хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы). Җөмлә ахырында тыныш билгеләре: нокта, сорау һәм өндәү билгеләре. Хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы җөмләләрнең интонацион үзенчәлекләре(гамәли үзләштерү).Баш һәм иярчен кисәкләр турында төшенчә. Ия һәм хәбәр. Җөмләдә сүзләр бәйләнешен билгеләү. Җөмләдә сүз тәртибе. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында төшенчә.

**Сүзтезмә**. Сүз, сүзтезмә, җөмләнең охшаш һәм аермалы яклары. Сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне таный белү. **Бәйләнешле сөйләм**

Текст. Текстның темасын, төп фикерен билгеләү, абзацларга бүлү. Тасвирлаучы һәм хикәяләүче текстларның төп үзенчәлекләре. Сөйләм этикасы белән таныштыру.

**4 нче сыйныф**

**Сүз . Телнең сүзлек байлыгы .Сүзнең лексик мәгънәсе.** Сүз һәм аның мәгънәсе, бер генә мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр, алынма сүзләр, синоним,антоним, омонимнар.Сүзне туры һәм күчерелмә мәгънәдә куллану. Искергән һәм яңа сүзләр. Бу белемнәрне гамәли сынап карау.Татарча-русча, русча- татарча сүзлекләр, орфографик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге .

**Сүз төзелеше**

4 нче сыйныфта ―Сүз төзелеше‖ темасы тагын да тирәнәйтелә: ясалма, кушма,парлы, тезмә сүзләрнең, ясалышы һәм дөрес язылышы, рус теленнән татар теленә кергән алынма кушма сүзләрнең үзенчәлекләре; сүз төзелешенә анализ ясау ,кушма сүзләрдә ь һәм ъ хәрефләренең язылыш кагыйдәләре, сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә сүз ясагыч кушымчаларның ялгану тәртибе. Сүз төзелешенә анализ.

**Сүз төркемнәре. Исем**

Мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге урыны турында кабатлау. Исемнәрнең хәбәр булып килүләренә күзәтүләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше. Калын һәм нечкә төрләнеш. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә кушымча ялгау. Килеш кушымчаларының дөрес язылышы. Баш килеш. Бу формада исемнәрнең җөмләдә ия, хәбәр, иярчен кисәк була алулары. Төшем килешенең мәгънәсе, җөмләдәге функциясе. Күплек сандагы исемнәрнең килешләр белән төрләнеше. Төрле килешләрдә исемнәрнең бәйлекләр белән кулланылуы.

**Фигыль**

Фигыль - катлаулы сүз төркеме. 4 нче сыйныфта 1-3 нче сыйныфта үткән материал искә төшерелә һәм хикәя фигыльнең билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман формалары; киләчәк заман формалары: билгесез киләчәк заман, билгеле киләчәк заман турында яңа мәгълүмат өстәлә. Фигыльнең барлык һәм юклык формалары.

Боерык фигыль. Боерык фигыльнең мәгнәсе , зат-сан белән төрләнеше. Боерык фигыльне куллану, дөрес язу.Фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе, антоним Һәм синоним фигыльләр турында мәгълүмат бирү.

**Сыйфат**

Сыйфат дәрәҗәләре. Дәрәҗә формаларының ясалышы, дөрес язылышы һәм кулланылышы. Сыйфатның җөмләдәге роле (иярчен кисәкләр һәм хәбәр булып килүе).Сыйфатларның туры һәм күчерелмә мәгънәдә кулланылуы.Антоним сыйфатлар, синоним сыйфатлар.

**Алмашлык**

Алмашлык – мөстәкыйль сүз төркеме. Ул сөйләмдә башка сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, сан һәм рәвешне) алыштырып килә. Алмашлык предметны яки билгене генә белдерми , ул бары тик үзе алыштырып килә торган сүз төркеменең грамматик билгеләренә ия була. Алмашлыкларның җөмләдәге роле. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы кабатлана һәм сорау алмашлыклары турында яңа мәгълүмат бирелә. Килеш сораулары сорау алмашлыкларына керәләр. . Алмашлыкларның сөйләмдә кулланылышы.

**Сан**

Сан предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме. Сан исем белән кулланылганда төрләнми. Җөмләдәге роле. Кайбер сан төркемчәләре :микъдар саннары, тәртип саннары.

**Рәвеш**

Рәвеш - мөстәкыйль сүз төркеме, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә.Рәвешләрнең җөмләдәге роле.Морфологик яктан - төрләнми. Ул ничек? кайчан? кая? кайда? никадәр? күпме ? кебек сорауларга җавап бирәләр. Эш яки хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә торган сүз төркеме.Сөйләмдә актив кулланыла торган рәвешләр, аларның дөрес язылышы.

**Кисәкчәләр**

Кисәкчәләр турында беренче мәгълүмат 3 нче сыйныфта бирелә. Кисәкчәләр (*да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит*). Аларның дөрес язылышы.

Кисәкчәләр сүз яки җөмләгә төрле төсмер өстәү өчен кулланылуы ачыклана.Кисәкчәләр аерым торганда мәгънә белдерми. Бик күп кисәкчә күп мәгънәле була,һәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә карап үзгәрә.

**Бәйлекләр**

1-3 нче сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау. Бәйлек- ярдәмче сүз, шуңа күрә, төшенчәдә төп урынны бәйлекнең функциясе, үтәгән хезмәте алып тора: бәйлекләр сүзләрне бәйлиләр.Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә күзәтүләр. Бәйлек төшенчәсе грамматик категория итеп аңлатыла.

**Сүзтезмә**

4 нче сыйныфта сүзтезмәләргә шактый эзлекле мәгълүмат бирү күздә тотыла : сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәләрнең барлыкка килү юлларын ныгыту, сүзтезмәдәге ияручә һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү.

**Җөмлә**

Җөмләнең баш кисәкләре. Баш һәм иярчен кисәкләрнең аермасы. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Ия белән хәбәр билгеләмәсе . Җыйнак һәм җәенке җөмләләр .Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч. Аергычка билгеләмә бирү Һәм аның сыйфат белән белдерелүе .**Җөмләнең тиңдәш кисәкләре**

Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең үзара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешен төшендерү, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләренең куелышын аңлату. Тиңдәш ияле һәм тиңдәш хәбәрле җөмләләр.Тиңдәш кисәкләр арасында ***һәм, я, да-дә, та-тә, ә, ләкин*** теркәгечләре, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре. Эндәш сүзләртурында төшенчә бирү. Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләрен куярга өйрәтү.

Гади һәм кушма җөмләләр турында төшенчә бирү. Составында 2-3гади җөмлә булган кушма җөмләләр**.** Тезмә кушма җөмләләрдә ***һәм, ә, ләкин, әмма*** теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре

**Бәйләнешле сөйләм**

Сөйләм, аның тормыштагы роле. Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү.

Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге. Текстка исем бирү.

Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә.

Текстка исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләрен билгеләү, җөмлә һәм текст кисәкләре эзлеклелеген төзәтү.

Текстның планын төзү. Бирелгән план буенча үз текстыңны төзү.

Сурәтләү һәм хикәяләү характерындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре.

Котлау тексты һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, үз текстыңны төзү һәм бирелгән текстларны тикшереп төзәтү, текстта синонимнар, антонимнар куллану.

Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (билгеләмәләрен ятламыйча): бирелгән текстны тулысынча файдаланып яки аерым урыннарын (сүзләрен) сайлап алып языла торган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү рәвешендәге сочинение һ.б.